РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Аксубаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль
районы башкарма
комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

« 12 » 05 2020

№ 278

Аксубаево

Аксубай муниципаль районының
мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре
эшчәнлеген яңарту турында

Татарстан Республикасы Аксубай районында санитария-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус инфекциясе таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм "Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында" 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәреш кертү хакында" 2020 елның 10 маендагы 374 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Аксубай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү, балаларны карау һәм тәрбияләү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә тәрбияләнүчеләрне 2020 елның 12 маеннан башлап кабул итүне яңадан башларга.
2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең эшләми торган көннәр чорында эшләве турында» 2020 елның 29 апрелендәге 267 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http: //aksubayevo. tatarstan. ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http: //pravo. tatarstan. ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Горбунов